**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"29" ноябрь 2020 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1.Җирле әһәмияттәге юлларга хезмәт күрсәтү:

- авыл урамнарындагы юлларны төзекләндерү (вак таш сатып алу, җәю һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү)

2) Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу, урнаштыру һәм хезмәтләр өчен түләү;

3) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

-Комсомольская һәм Татарстан урамнары арасындагы чокыр үзәнен куаклардан чистарту,төзекләндерү, калдыкларны утильләштерү, транспорт хезмәтләре һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Кошар авылы территориясен чистарту, хезмәт өчен түләү.

4) Коеларны төзекләндерү:

- Комсомольская һәм Октябрь урамнарында коеларны төзекләндерү ( материаллар сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү)

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Салахов И.И.